

Һәр авылынын vз чишмәсе булган кебек, Дубенка районы Ломат авылыннын да чишмәләре бар. Элек яшь киленнәр баш юарга кизләvдән киянтәләр белән су ташысалар, хәзер машина, мотоблок, велосипедларда су очен авыл халкы гына тvгел, Саранск, Чамзинкага алып китәләр. Чишмәләренен суы чәйгә бик яхшы: тәмле, матур тосле була.       Гомер барышында Ломатта барлыгы алты чишмә булган, ә хәзер дvртесе генә калган: кырдагы икесе, Ломат авылы халкынын мал-туар котvләре булмаганга, кирәге юк һәм чистартучылары юк, шуна жәйнен эссесендә беркемнен дә сусавын баса алмыйлар - югалганнар.

300 еллап булган биографияле “Бяркиз кизләве” турында сvзебез. Чишмәнен исеме Ломатта гомер итvче Бяркизовлар гаиләсе фамилиясе белән аталган. Суы йомшак, сабынласан - сабыны юылып бетми тосле. Заманында биология фәне буенча авыл балаларына белем биргән укытучы  Абрамов Александр Тимофеевич



Бяркиз чишмәсенен суына анализ ясаган; су составында йод барлыгын ачыклаган. Ломатлылар чишмәне хөрмәтләп карыйлар, Семипалат урамы ир-егетләре язын - печәнен чабалар, хатын-кызлары - тирә-ягына чәчәкләр утырталар, ә кышын бозын чабалар, сукмакларын кардан чистарталар. Еллар узу белән чишмә туза: су эчендәге идәне череми. Ә оске олеше чери. Мордовиядә “Самооблажение...” Программасы эшли башлагач, кvп авыллар халкы байтак нәрсәләрне эшләп жибәрде. Бу Программа кешеләр очен зур ярдәм, чонки кирәккә дип акчанын бер олешен халык бирсә, хокvмәт дvрт

тапкыр кvп бирә. Шулай Ломат халкы да эшкә керешә. Чишмәне тозекләргә карар кыргач, акча жыя башлыйлар, әмма ниндидер сәбәп эшне туктата. Эш башлап жибәргән кешеләр максатларына еллар vткәч ирешә: Бяркиз чишмәсен барыбер тозекләндерәләр. Авыл халкы Шамиль Аллям улы Ряхмятуллов – оештыручы;



Рафик Ахать улы Муракаев – сварка; Рифат Рәшит улы Узбяков, абыйлы-энеле Рәхим, Рамиль Зульхарнеевлар, Тимур Рашит улы Муракаев, Ринат Амин улы Маняков, Альмир белән Раиль Мухетдиновлар, Ринат Фатих улы Маштаков, Рәшит Фоат улы Фатхиев ремонтлыйлар. Рамиль Куренковнын тырышлыгы буенча Чамзинкадан труба, шебенка алып киләләр. Авылдан читтә яшәvчеләр дә катнаша бу изге эштә: Чамзинкадан Амиров Рашит белән Рахметуллов Рафаиль ярдәм иттеләр.
Бvген теләсә кем килеп Бяркиз чишмәсенен шифалы суын эчә ала. Бер тәмен татыгач, Ломатнын тәнгә дәва, жанга сихәт бирә торган чишмәсе суын vзләре белән дә алып китәләр.

**Мязидә МУРАКАЕВА**